ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«_14_» _апрель_ 2018 ел № _340_

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү« программасы буенча торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү һәм исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 14.07.2016ел, №794 карарына үзгәрешләр кертү турында (2017 елның 14 августындагы 948 номерлы редакциясендә)**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында" башкарма комитет карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 14 июлендәге 794 номерлы карары (2017 елның 14 августындагы 948 номерлы редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алу (төзү) хокукын исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү һәм аны яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609008516

Җитәкче И.Ә.Галимуллин